| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И<br>СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ<br>РЕСПУБЛИКИ<br>ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ<br>БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ<br>СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

29.08.2022 Казан ш. №813

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.06.2016 №317, 12.07.2018 №550, 10.09.2018 №842, 31.05.2019 №414, 16.11.2019 №1040, 15.05.2020 №297, 20.07.2020 №521, 28.09.2020 №675, 07.06.2021 №403, 19.10.2021 №770, 16.06.2022 №554 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 29 августындагы 813 номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгына кертелә торган үзгәрешләр

Боерык преамбуласында «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең федераль дәүләт стандартын раслау турында» 2014 елның 17 апрелендәге 262н номерлы боерыгы белән» сүзләрен «Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру процессы стандартын раслау турында» 2022 елның 25 февралендәге 81н номерлы боерыгы белән» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында» 2015 елның 25 августындагы 591 номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентында:

1-3 бүлекләрне киләсе редакциядә бәян итәргә:

«1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү стандартын, тәртибен, гамәлләрнең (административ процедураларның) составын, аларның эзлеклелеген һәм аларны үтәү срокларын билгели (алга таба – дәүләт хезмәте).

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр – законнарда билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр).

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган үткәрә торган

анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән мөрәҗәгать итүченең тиешле билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү) профильне яңасына үзгәртү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт оешмалары (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге, ХМҮ) тарафыннан күрсәтелә. Халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләренә карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы гамәлгә ашыра.

Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасының тиешле муниципаль берәмлекләре территориясендә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан мөрәҗәгать итүченең яшәү урыны буенча күрсәтелә.

2.2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге (алга таба - КФҮ) һәм (яки) КФҮнең ерактагы эш урыны аша бирелергә мөмкин.

КФҮ белгече тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм гаризаны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителми.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

а) укытуга юллама (Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Халыкның мәшгульлегенә булышлык итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә бәйле документларның рәвешләрен раслау турында» 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерыгы (алга таба – 2021 елның 20 октябрендәге 738н номерлы боерык) белән расланган форма буенча);

б) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2022 елның 25 февралендәге 81н номерлы боерыгы белән расланган Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү буенча халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыру процессы стандартына (алга таба – Стандарт) (әлеге Регламентка 4 нче кушымта) 2 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә, түбәндәгеләрне үз эченә ала:

алар буенча һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү гамәлгә ашырыла ала торган һөнәрләрнең (белгечлекләрнең) киңәш ителә торган исемлеге;

укыту өчен тәкъдим ителгән укыту программалары исемлеге;

укыту процессын оештыру турында белешмәләр (һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау һәм халыкның мәшгульлек үзәге белән мөрәҗәгать итүче арасында белем алуга юллама алу турында шартнамә реквизитлары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманың исеме; курс программасының исеме; укуның башлану һәм тәмамлану даталары);

мөрәҗәгать итүчене һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирлеккә юллаганда финанс ярдәме күрсәтелүе турында белешмәләр».

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе мәшгульлек һәм хезмәт мөнәсәбәтләре өлкәсендә «Работа в России» бердәм цифрлы платформасында (https://www.trudvsem.ru/) (алга таба – «Работа в России» порталы) теркәлә».

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә бирелә (җибәрелә):

«Работа в России» порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталыннан (http://www.uslugi.tatarstan.ru (алга таба – Татарстан Республикасы порталы) файдаланып, электрон документ рәвешендә;

мөрәҗәгать итүчегә шәхсән кәгазь чыганакта.

## 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. «Работа в России» порталыннан файдаланып дистанцион форматта дәүләт хезмәте «Работа в России» порталында дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза кабул ителгәннән соң егерме эш көненнән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.2. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килеп йөрү зарурлыгы булган очракта, дәүләт хезмәте «Работа в России» порталында гариза кабул ителгәннән соң утыз эш көненнән дә соңга калмыйча күрсәтелә.

2.4.3. Бәяләмә мөрәҗәгать итүчегә «Работа в России» порталыннан формалаштырылган көнне җибәрелә.

2.4.4. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.4.5. Инвалид булып торган мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәте күрсәтү «Федераль инвалидлар реестры» (алга таба – ФИР) федераль дәүләт мәгълүмат системасында булган инвалидлык турында белешмәләр, ә тиешле белешмәләр булмаса, мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән документлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

ФИР аша инвалидлык турында кирәкле белешмәләрне алу мәшгульлек үзәге тарафыннан «Ведомствоара электрон багланышларның бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы) ярдәмендә мәшгульлек үзәге тарафыннан электрон документ рәвешендә җибәрелә торган ФИР адресына ведомствоара гариза формалаштыру юлы белән халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан башкарыла.

ФИР системасыннан кирәкле белешмәләрне алу вакыты мөрәҗәгать итүче гариза тапшырган датадан башлап җиде эш көненнән артмаска тиеш.

2.4.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү мәсьәләләре буенча язмача мөрәҗәгатькә, электрон почта, факсималь элемтә чараларын кулланып алынган мөрәҗәгатьне дә кертеп, җавап әзерләү срогы мөрәҗәгатьне теркәү көненнән башлап 15 календарь көннән артмаска тиеш.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Татарстан Республикасы Порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм белешмәләр исемлеге түбәндәгеләрне үз эченә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (тәкъдим ителә торган үрнәге Стандартка 1 нче кушымтада китерелгән ) (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

эшсез гражданинны теркәү вакытында мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар һәм (яки) белешмәләр нигезендә «Работа в России» порталына кертелгән белешмәләр.

2.6.2. Гариза мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы буенча яисә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдиме белән риза булган очракта бирелә.

Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан электрон рәвештә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинет аша;

Татарстан Республикасы порталы аша;

күпфункцияле үзәк яки күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыны аша;

халыкның мәшгульлек үзәгенә «Работа в России» порталына керүне тәэмин итеп, шәхсән килгән очракта.

2.6.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында электрон рәвештәге гариза халыкның мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану турында» 2013 елның 25 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә гади электрон имза куллану кагыйдәләре нигезендә алынган гади электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән яки көчәйтелгән квалификацияле булмаган,

тикшерү сертификаты электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада булдырылган һәм кулланыла торган имза белән имзалана.

2.6.4. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә яки дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенә электрон формада гариза бирүдә ярдәм итүне сорап мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән мөрәҗәгать итүчеләргә «Работа в России» порталына, Татарстан Республикасы порталына керү мөмкинлеге бирелә, шулай ук кирәкле консультация ярдәме күрсәтелә.

Халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать иткән затта «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итә торган инфраструктурада бердәм идентификация һәм атутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында исәпкә алу язуы булмаса, халыкның мәшгульлек үзәге яки күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны, халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итүче зат риза булган очракта, әлеге системада мөрәҗәгать итүченең процедуралар узып бетерүен тәэмин итә.

2.6.5. Халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән барган очракта, мөрәҗәгать итүче паспортын яисә аны алыштыра торган документны күрсәтә.

2.6.6. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында алына торган документлар (белешмәләр):

паспортның хакыйкыйлыгы турында мәгълүмат – Россия Эчке эшләр министрлыгы (ведомство мәгълүмат системасы);

яшәү урыны буенча теркәлү турында белешмәләр – Россия ЭЭМ (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт эшчәнлеге, хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру факты турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

хезмәт стажы турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

мәҗбүри пенсия иминияте өчен иминият кертемнәре түләнгән соңгы эш (хезмәт) урыны буенча түләүләр һәм башка төрле бүләкләүләр турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (ведомство мәгълүмат системасы);

инвалидлык турында белешмәләр (инвалидны тернәкләндерүнең яки абилитацияләүнең хосусый программасыннан өземтә (гражданин тарафыннан гаризада тиешле мәгълүмат күрсәтелгән очракта) – Россия Федерациясе Пенсия фонды («Инвалидларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

белеме, квалификациясе турында белешмәләр – Рособрнадзор («Белем турында һәм (яки) квалификация, белем алу турында документлар турында мәгълүматларның федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасы);

лаеклы ял алды яшендәге гражданнарга кертелү турында белешмәләр – Россия Федерациясе Пенсия фонды (Социаль тәэмин итү бердәм дәүләт мәгълүмат системасы);

2.6.6. Ведомствоара гарызнамә ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасыннан һәм аңа тоташтырыла торган ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең төбәк системаларыннан файдаланып, электрон документ формасында җибәрелә.

2.6.7. Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон рәвештә дә, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

2.6.8. Әлеге дәүләт хакимияте органнары тарафыннан документлар һәм мәгълүматның тапшырылмавы (вакытында тапшырылмавы) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезе була алмый.

## 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге

2.7.1. Халыкның мәшгульлек үзәгендә мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегендә күрсәтелгән документның тапшырылмавы;

документларда бетерелгән, өстәп язылган урыннарның, сызылган сүзләрнең һәм төзәтмәләрнең Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган булуы;

халыкның мәшгульлек үзәгенә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы һәм «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) федераль законнардагы таләпләргә туры китереп, электрон имза белән имзаланмаган (таныкланмаган) электрон документлар формасында гариза һәм документлар (документларның күчермәләрен) тапшыру;

күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланмаган очракта, мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән мөрәҗәгать иткәндә төп документларның күрсәтелмәве.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

эшчәнлек (йөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнаштыру, һөнәргә уку узу һәм өстәмә һөнәри белем алу) максатларында мөрәҗәгать итүчене һөнәри юнәлеш алуга юллау (алга таба – һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте);

мөрәҗәгать итүчене, гражданин тарафыннан зарури медицина таныклавы узуны таләп итә торган һөнәр (белгечлек) сайлап алынган очракта, медицина таныклавына юллау.

2.8.2. Россия Федерациясе гражданины паспортын яки аны алмаштыра торган документның, чит ил гражданинының шәхесен һәм гражданлыгын таныклый торган документларның, гражданлыгы булмаган затның шәхесен таныклый торган документларның булмавы яки аларны күрсәтүдән баш тартуы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

2.8.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге очракларда туктатыла:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 2 ноябрендәге 1909 номерлы карары белән расланган Эшсез гражданнарны теркәү кагыйдәләре нигезендә билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган мөрәҗәгать итүченең һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүгә мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзелгән мизгелгә кадәр теркәү исәбеннән төшерелүе очрагында;

гаризаны кире алган очракта;

мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә беренчел әңгәмә узу өчен әлеге Регламентның 3.7 пунктында каралган тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан билгеләнгән датада килмәгән очракта;

мөрәҗәгать итүче әлеге Регламентның 3.12 пунктының «б» пунктчасындагы дүртенче абзацында билгеләнгән срокта, «Работа в России» порталын кулланып, һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрнең (белгечлекнең) сайланган варианты турындагы мәгълүматны халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәгән очракта;

мөрәҗәгать итүче һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау турында шартнамәне имзалаудан баш тарткан очракта;

әлеге Регламентның 3.18 пунктының икенче абзацында билгеләнгән срокта мөрәҗәгать итүченең медицина таныклавын узу турындагы бәяләмәне халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшырмавы очрагында;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайланган һөнәр (белгечлек) һәм сайланган белем бирү программасы варианты нигезендә белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешманың сайланган варианты турында мөрәҗәгать итүченең әлеге Регламентның 3.24 пунктының «б» пунктчасындагы икенче абзацында билгеләнгән срокта «Работа в России» порталын кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә юлламавы;

белдерүдә күрсәтелгән ысул белән мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәге белән үзара хезмәттәшлек итә башларга тиешле, халыкның мәшгульлек үзәге белдерүендә күрсәтелгән датадан башлап бер айдан артып киткән чорда мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белән хезмәттәшлек итмәве.

2.8.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар «Работа в России» порталында, Татарстан Республикасы порталында теркәлә һәм халыкның мәшгульлек үзәгендә мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.10.1. Мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткән очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза «Работа в России» порталын кулланып, чират тәртибендә бирелә. Чиратта тору вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.10.2. Вакыты һәм датасы алдан килештерелгән очракта, мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә «Работа в России» порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны көтү вакыты биш минуттан артмаска тиеш.

Дәүләт хезмәтеннән файдаланучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.11.1. Гариза мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелгән көнне халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан кабул ителгән дип санала.

2.11.2. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гариза ял (бәйрәм) көненнән соңгы эш көнендә теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.

2.12.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла. Көтү залларында (бүлмәләрдә) мәгълүматлар, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза формалары урнаштырылган мәгълүмат стендлары урнаштырыла.

2.12.3. Инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларда (алга таба – объект) законнар һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, халыкның мәшгульлек үзәкләре белгечләре тарафыннан түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) объектларга каршылыксыз керү һәм чыгу мөмкинлеге;

б) хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, шул исәптән хезмәт күрсәтә торган объект хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче

технологияләр, шулай ук алмаштырыла торган кресло-коляска ярдәмендә дә, объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге;

в) объектка керә торган урында транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска кулланып һәм, кирәк булганда, хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр ярдәмендә дә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү буенча тотрыклы җитешсезлекләре булган инвалидларга объект территориясе буйлап хәрәкәт итәргә булышу;

д) инвалидка объектка кергәндә һәм аннан чыкканда ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының уңайлы маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектлардан һәм күрсәтелә торган дәүләт хезмәтеннән каршылыксыз файдалана алуын тәэмин итү өчен, алар яшәешендәге чикләүләрне исәпкә алып, кирәкле мәгълүмат чараларын тиешенчә урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле тавышлы һәм күрсәтмә мәгълүматларны, шулай ук язуларны, тамгаларны һәм текстлы башка төрле һәм Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контраст фонда башкарылган тамгалардан график мәгълүматны кабатлау;

ж) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Сукырларны йөртүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ рәвешен һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелә торган һәм аның махсус рәвештә өйрәтелгән булуын раслаучы документы булган очракта, объектка озата йөри торган этне кертү.

2.12.4. Инвалидларга законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләргә туры китереп, дәүләт хезмәтләре күрсәтү мөмкинлеге бирү өчен түбәндәге уңайлы шартлар тудырыла:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәтеннән файдалану өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында кирәкле ярдәмне күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ишарә теленнән файдаланып, сурдотәрҗемәчене, тифлосурдотәрҗемәчене объектка кертүне дә исәпкә алып, дәүләт хезмәте күрсәтү;

к) халыкның мәшгульлек үзәкләре хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә дәүләт хезмәтеннән файдалануга комачау итә торган каршылыкларны үтүдә кирәкле башка ярдәм күрсәтү;

г) дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында (шул исәптән мәгълүмат стендында да) Брайльнең рельефлы-нокталы хәрефләре белән һәм контрастлы фонда башкарылган документлар, белдерүләр, күрсәтмә аңлатмалар күчермәләренең, шулай ук регистратурада аудиоконтур булуы.

2.12.5. 2016 елның 1 июленнән соң реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга һәм чараларга карата дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектларның инвалидлар өчен үтемлелеген тәэмин итү өлешендәге таләпләр.

## 2.13. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.13.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре:

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм чорлары турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү үрнәкләре турында мөрәҗәгать итүче өчен индивидуаль яки гавами (телдән яки язмача) мәгълүмат бирү мөмкинлеге (шәхси кабул иткәндә, телефон элемтәсе, электрон почта чараларын кулланып, массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләр, мәгълүмати материаллары (брошюралар, белешмәлекләр, буклетлар һ.б.) нәшер итү юлы белән, «Работа в России» порталында, Татарстан Республикасы порталында мәгълүмат урнаштыру юлы белән);

мөрәҗәгать итүче өчен дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаларның һәм башка документларның үрнәкләрен алуны, шул исәптән аларны күчереп алу һәм электрон рәвештә тутыру мөмкинлеге белән дә, тәэмин итү;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтү вакытының саклануы;

дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе, шул исәптән телефон элемтәсе, электрон почта аша, «Работа в России» порталы, Татарстан Республикасы порталы, күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнеңерактагы эш урыны, шулай ук Министрлыкның рәсми сайтында мәгълүмат алу мөмкинлеге;

күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыны аша электрон рәвештә гариза бирү мөмкинлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтә торган хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдалануга комачаулый торган каршылыкларны үтеп чыгарга ярдәм итү.

2.13.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфатлы булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан халыкны эш белән тәэмин итү турында Россия Федерациясе законнарындагы мәҗбүри таләпләрнең, дәүләт хезмәте күрсәткәндә әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлеше;

дәүләт хезмәте күрсәтү чорларының үтәлүе;

әлеге Регламентта билгеләнгән административ процедураларның эзлеклелеге саклану;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезлелеге;

дәүләт хезмәтен күрсәтү мәсьәләсе буенча нигезле шикаятьләрнең булмавы;

2.13.3. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең халыкның мәшгульлек үзәге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керү вакыты 20 минуттан артмый.

2.13.4. Дәүләт хезмәте (консультацияләү һәм гариза һәм резюмены кабул итүдән тыш) күпфункцияле үзәктә, күпфункцияле үзәкнең читтәге эш урыннарында күрсәтелми.

Мөрәҗәгать итүче күпфункцияле үзәккә, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарына мөрәҗәгать иткәндә, гариза һәм резюме теркәлгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча мәшгульлек үзәгенә тапшырыла.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән үзара хезмәттәшлек итү тәртибе халыкның мәшгульлек үзәге белән күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннары белән төзелә торган үзара хезмәттәшлек турындагы килешү белән җайга салына, ә күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының мөрәҗәгать итүчеләр белән – күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарының эш регламенты белән.

2.13.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан «Работа в России» порталындагы шәхси кабинеты аша, Татарстан Республикасы порталында, КФҮ, КФҮнең ерактагы урынында алынырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте күрсәтү, хезмәт күрсәтү тәртибе һәм башка документлар турындагы белешмәләрне карау «Работа в России» порталындагы шәхси кабинетында, Татарстан Республикасы порталында мөрәҗәгать итүчене алдан авторизацияләмичә башкарыла.

«Работа в России» порталындагы шәхси кабинетта, Татарстан Республикасы порталында авторизация узганнан соң мөрәҗәгать итүче түбәндәге мөмкинлекләргә ия була: дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны тапшыру, дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында белешмәләр алу, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүмат алу.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.14.1. Дәүләт хезмәте, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүдән, теркәлгән гражданнарга һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәр (белгечлек) вариантлары исемлеген җибәрүдән тыш, электрон рәвештә күрсәтелми.

2.14.2. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче түбәндәгеләргә хокуклы:

а) «Работа в России» порталында, Татарстан Республикасы порталында урнаштырылган дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) «Работа в России» порталын, Татарстан Республикасы порталын кулланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирергә;

в) электрон формада тапшырылган дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

г) «Работа в России» порталыннан, Татарстан Республикасы порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатына бәя бирергә;

д) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен электрон белдерү формасында алырга;

е) дәүләт хезмәтләре күрсәтә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган «Работа в России» порталы, Татарстан Республикасы порталы ярдәмендә Министрлык, шулай ук аның вазыйфаи затлары, дәүләт хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

2.14.3. Гариза, туры килә торган эш вариантлары исемлеге Татарстан Республикасы Порталы, «Работа в России» порталы аша җибәрелә ала.

2.14.4. Мөрәҗәгать итүче КФҮ мөрәҗәгать иткән очракта, гаризаны халыкның мәшгульлек үзәгенә тапшыру КФҮ белән халыкның мәшгульлек үзәге арасындагы килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм чорларда, ләкин гаризаны КФҮ теркәгәннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

2.14.5. Гаризаны төзү, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвештә тапшыру зарурлыгыннан тыш, «Работа в России» порталында яки Бердәм порталда гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.14.6. Мөрәҗәгать итүчеләрне халыкның мәшгульлек үзәгенә кабул итү өчен язу (алга таба – кабул итү өчен язу) Татарстан Республикасы порталы, халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгендә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә теләсә нинди буш кабул итү датасына һәм вакытына язылу мөмкинлеге бирелә.

Татарстан Республикасы порталы аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен мөрәҗәгать итүчегә системада сорала торган белешмәләрне күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясен, исемен һәм атасының исемен (булган очракта);

электрон почта адресын (ихтыярына карап);

кабул итүнең теләнгән датасын һәм вакытын.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан алдан язылу барышында күрсәтелгән белешмәләр мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә тапшырылган документлардагы белешмәләргә туры килмәсә, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Кабул итүгә алдан язылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә талон-раслама чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Әгәр мөрәҗәгать итүче электрон почта адресын күрсәтсә, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Мөрәҗәгать итүче теләсә кайсы вакытта Татарстан Республикасы порталы яки халыкның мәшгульлек үзәге телефоны аша алдан язылудан баш тартырга хокуклы.

Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә идентификацияләүне һәм аутентификацияләүне узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен алдан ук билгеләп куелырга тиешле кирәкле

вакыт озынлыгын исәпләүдә кирәкле белешмәләрне тапшырудан тыш, мөрәҗәгать итүчедән башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

2.14.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.14.8. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә кулланыла:

«Работа в России» порталы;

ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы.

2.14.9. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары.

3.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге административ процедураларны (гамәлләрне) үз эченә ала:

а) белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар белән һөнәри белем бирү яки өстәмә һөнәри белем бирү турында шартнамәләр төзүне оештыру;

б) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү;

в) мөрәҗәгать итүченең гаризасын кабул итү;

г) мөрәҗәгать итүче белән беренчел әңгәмә үткәрү;

д) мөрәҗәгать итүчегә һөнәри юнәлеш буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү;

е) һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрне (белгечлекне) сайлап алу һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерү;

ж) мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавын узу турында белдерү җибәрү һәм мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавына юллама бирү;

з) элегрәк сайланган һөнәр (белгечлек) буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата каршылыклар булуы турында медицина бәяләмәсе тапшырылган очракта, мөрәҗәгать итүче белән килештереп, ул һөнәри белем алачак яки өстәмә һөнәри белем алачак башка төрле һөнәрне (белгечлекне) сайлап алу һәм килештерү;

и) мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) һәм белем бирү программасы нигезендә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешманы сайлау һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерү;

к) һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алуга юллама бирү турында шартнамә рәсмиләштерү һәм мөрәҗәгать итүчегә бирү;

л) мөрәҗәгать итүчене укыту турындагы белешмәләрне «Работа в России» порталына кертү;

м) мөрәҗәгать итүчене һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен башка җирлеккә юллаган очракта, аңа финанс яктан ярдәм күрсәтү;

н) мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә формалаштыру һәм җибәрү;

о) техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталындагы мәгълүматларны анализлау

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче турында «Работа в России» порталында булган белешмәләрне, шулай ук әлеге Регламентның 2.6.6 пунктында каралган ведомствоара гаризаларны җибәрү юлы белән алынган белешмәләрне анализлый.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче турындагы мәгълүматларны анализлау.

3.3. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыру һәм җибәрү

Халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталыннан файдаланып, дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим формалаштыра һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдим шулай ук «Работа в России» порталында автомат рәвештә формалашырга мөмкин.

Үтәү вакыты: процедура тәкъдим формалаштырылган көнне башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдим җибәрү.

3.4. Мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгенә тәкъдимнәрне карау нәтиҗәләрен җибәрү турында хәбәр итү

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә:

«Работа в России» порталы ярдәмендә халыкның мәшгульлек үзәгенә дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау нәтиҗәләрен җибәрү турында;

дәүләт хезмәте күрсәтү турында тәкъдимне карау нәтиҗәсен «Работа в России» порталын кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрү срогы турында.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнән баш тартуы яисә тәкъдим белән ризалашуы.

Үтәү вакыты: мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне карау срогы билгеләнми.

3.5. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимнән баш тартуы (шул исәптән мөрәҗәгать итүченең әлеге тәкъдимне карау нәтиҗәләрен «Работа в России» порталын кулланып, халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәве).

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән баш тарту турында хат алынган көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнән баш тартуы һәм бердәм цифрлы платформада теркәү.

3.6. Мөрәҗәгать итүче белән беренче әңгәмәне дистанцион формада үткәрүне килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге:

а) беренчел әңгәмәне дистанцион формада үткәрү өчен мөрәҗәгать итүче белән күрсәтелгән телефон номеры буенча элемтәгә керә;

б) һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу өчен һөнәрләр (белгечлекләр) турындагы теләкләре турында мөрәҗәгать итүчедән аныклый һәм «Работа в России» порталына кертә;

в) беренчел әңгәмә үткәрү формасын, датасын һәм нәтиҗәсен «Работа в России» порталында терки.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беренчел әңгәмә үткәрү.

3.7. Мөрәҗәгать итүче белән беренчел әңгәмә үткәрүне килештерү

Гаризада күрсәтелгән телефон номеры буенча мөрәҗәгать итүче белән дистанцион формада беренчел әңгәмә уздыру мөмкин булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге, гаризаны кабул иткән көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, «Работа в России» порталын кулланып, беренчел әңгәмә уздыру өчен мөрәҗәгать итүче килергә тиешле датаны һәм вакытны билгели.

Халыкның мәшгульлек үзәге, «Работа в России» порталын кулланып, датасын һәм вакытын күрсәтеп, беренчел әңгәмә уздыру өчен мөрәҗәгать итүчегә халыкның мәшгульлек үзәгенә килергә тиешлеге турында белдерү җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән датада һәм вакытта халыкның мәшгульлек үзәгенә беренчел әңгәмә узу өчен килмәгән очракта, «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүче өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә кабат килү датасын һәм вакытын билгели, мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерүне җибәрә.

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә беренче тапкыр билгеләнгән датадан соң шәхси килмәгән көннән башлап 15 календарь көн дәвамында халыкның мәшгульлек үзәгенә иң күбе ике тапкыр кабат килү көнен билгели.

Халыкның мәшгульлек үзәге билгеләгән даталарда мөрәҗәгать итүче билгеләнгән беренче датага шәхсән килмәгән көннән башлап 15 календарь көн эчендә мөрәҗәгать итүче беренчел әңгәмә узу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килмәсә, халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүченең беренчел әңгәмәгә килмәве турындагы белешмәләрне «Работа в России» порталында терки, дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта халыкның мәшгульлек үзәге дәүләт хезмәтен күрсәтү туктатылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмаган срокта мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрә.

Мөрәҗәгать итүче билгеләнгән датада һәм вакытта килгән очракта, халыкның мәшгульлек үзәге әлеге Регламентның 3.6 пунктының «б» һәм «в» пунктчаларында күрсәтелгән гамәлләрне башкара.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: беренчел әңгәмә көнен һәм вакытын килештерү.

3.8. Һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне мөрәҗәгать итүче белән килештерү

Мөрәҗәгать итүче һөнәрне (белгечлекне) сайлаганда кыенлык кичерсә, халыкның мәшгульлек үзәге:

а) эшчәнлек (һөнәр) өлкәсен сайлау, эшкә урнаштыру, беренчел әңгәмә

узган очракта һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне формалаштыра һәм мөрәҗәгать итүчегә җибәрә;

б) һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимне алган көннән башлап өч календарь көн узмаган срокта тәкъдимне карау нәтиҗәсен «Работа в России» порталын кулланып җибәрү кирәклеге турында мөрәҗәгать итүчегә мәгълүмат җиткерә. Мөрәҗәгать итүче ихтыярына карап, тәкъдимне карау нәтиҗәсе тәкъдимнән баш тарту яисә һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны юллау юлы белән, тәкъдим белән ризалашу була ала.

Күрсәтелгән мәгълүмат гражданинга җибәрелә торган һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы тәкъдимдә була.

Үтәү вакыты: процедура гариза кабул ителгән көннән соңгы киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тәкъдимнән баш тарту яки һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдиме белән ризалашу.

3.9. Мөрәҗәгать итүченең һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдименнән баш тартуын (шул исәптән тәкъдимне алган көннән соң өч календарь көн узмаган срокта һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү тәкъдимен карау нәтиҗәсе турындагы мәгълүматның мөрәҗәгать итүче тарафыннан җибәрелмәвен) халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталында терки.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән баш тарту турында хат алынган көннән соң эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең тәкъдимнән баш тартуы.

3.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү мөрәҗәгать итүче һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгән вакытка туктатып торыла. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза бирелгән көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.

3.11. Мөрәҗәгать итүчегә тәкъдим ителә торган һөнәрләр исемлеген сайлау

Халыкның мәшгульлек үзәге алар буенча мөрәҗәгать итүчене һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылырга мөмкин булган, тәкъдим ителә торган һөнәрләр (белгечлекләр) исемлеген «Работа в России» порталын кулланып сайлый, мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләр анализын исәпкә алып, шул исәптән:

тиешле эш эзләү максатларында мөрәҗәгать итүчене теркәгәндә «Работа в России» порталына кертелгән мөрәҗәгать итүче турындагы белешмәләр;

беренчел әңгәмәне уздырганда «Работа в России» порталына мөрәҗәгать итүче турында кертелгән белешмәләр;

һөнәри юнәлеш бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре (булган

очракта);

квалификация белешмәлекләрендә һәм (яки) һөнәри стандартларда булган хезмәткәр квалификациясенә карата таләпләргә карап;

эш бирүчеләр тарафыннан белдерелгән хезмәткәрләрнең сан исәбе һәм һөнәри-квалификация ягыннан ихтыяҗы, хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган һөнәрләр (белгечлекләр) турында белешмәләргә карап;

эшсез гражданнарга һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү өчен өстенлекле һөнәрләр (белгечлекләр) исемлегенә карап;

белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган мәгариф оешмалары исемлегендә булган һөнәри белем бирү һәм өстәмә һөнәри белем бирү программалары, һөнәрләр (белгечлекләр) турындагы белешмәләргә карап.

Үтәү вакыты: процедура беренчел әңгәмә үткәрелгән көннән соң килгән өч эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче өчен тәкъдим ителгән һөнәрләр (белгечлекләр) исемлеген «Работа в России» порталыннан файдаланып сайлап алу.

3.12. Һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрне (белгечлекне) сайлап алу һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерү

Халыкның мәшгульлек үзәге аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрне (белгечлекне) мөрәҗәгать итүче белән килештерү максатларында, «Работа в России» порталыннан файдаланып, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне җибәрә:

а) алар буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алу мөмкин булган һөнәрләрнең(белгечлекләрнең) киңәш ителә торган исемлеген;

б) белдерү, анда түбәндәге мәгълүмат була:

аның буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрнең (белгечлекнең) бер вариантын сайлап алу кирәклеге турында;

туры килә торган һөнәрнең булмавын билгеләү һәм аның буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрләрне (белгечлекләрне) яңадан сайлап алуны билгеләү мөмкинлеге турында;

«Работа в России» порталыннан файдаланып, алар буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алынырга мөмкин булган һөнәрләрнең (белгечлекләрнең) киңәш ителә торган исемлеген алган көннән соң киләсе бер эш көне эчендә алар буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрнең (белгечлекнең) сайлап алынган варианты турында мәгълүмат җибәрү кирәклеге турында.

Үтәү вакыты: процедура беренчел әңгәмә үткәрелгән көннән соң килгән өч эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрне (белгечлекне) сайлап алу һәм мөрәҗәгать итүче белән килештерү.

3.13. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайланган һөнәр (белгечлек) варианты турында мәгълүмат бирү (бирмәү)

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан халыкның мәшгульлек үзәгенә аның буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алыначак һөнәрнең (белгечлекнең)

сайлап алынган варианты турында әлеге Регламентның 3.12 пунктының «б» пунктчасының дүртенче абзацында билгеләнгән срок эчендә мәгълүмат җибәрелмәве «Работа в России» порталында теркәлә. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу хакта мөрәҗәгать итүчегә, «Работа в России» порталыннан файдаланып, хәбәр җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче сайланган һөнәр (белгечлек) варианты турында мәгълүмат җибәрергә тиеш булган көннән дә соңгы эш көненнән соңга калмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату.

3.14. Медицина учреждениеләре белән мөрәҗәгать итүчеләргә медицина таныклавын уздыруга шартнамәләр төзү

Халыкның мәшгульлек үзәге медицина учреждениеләре белән һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алуга җибәрер алдыннан мөрәҗәгать итүчеләргә медицина таныклавын уздыру буенча шартнамәләр төзи яисә медицина таныклавын узу чыгымнарын гражданинга компенсацияләү турында карар кабул итә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан мәҗбүри медицина тикшерүен таләп итә торган һөнәр (белгечлек) сайланган очракта башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: медицина учреждениеләре белән шартнамәләр төзү.

3.15. Медицина учреждениеләре белән төзелгән шартнамәләр турында мәгълүматларны теркәү

Халыкның мәшгульлек үзәге медицина учреждениеләре белән төзелгән шартнамәләр турында «Работа в России» порталына мәгълүмат кертә.

«Работа в России» порталында медицина учреждениеләре реестры формалаштырыла һәм алып барыла.

Үтәү вакыты: процедура шартнамәләр төзүгә карап гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: төзелгән шартнамәләр турында мәгълүмат кертү.

3.16. Мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавын уздыру турында белдерү җибәрү

Мөрәҗәгать итүче мәҗбүри рәвештә медицина таныклавын уздыруны таләп итә торган һөнәрне (белгечлекне) сайлаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәр буенча медицина таныклавын уздыру турында белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән сайлап алынган һөнәр (белгечлек) варианты алынганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавын уздыру турында белдерү җибәрү.

3.17. Мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавы узу өчен юллама рәсмиләштерү

Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә Стандартка 3 нче кушымтада китерелгән, киңәш ителә торган үрнәк буенча медицина учреждениесенә медицина таныклавы узу өчен юллама рәсмиләштерә.

Халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталын кулланып, мәҗбүри медицина таныклавы узуны таләп итә торган, аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәр буенча медицина таныклавы узуга юллама алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көнен күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән сайлап алынган һөнәр (белгечлек) варианты алынганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: медицина таныклавын узуга юллама алу өчен мөрәҗәгать итүчегә белдерү рәсмиләштерү һәм җибәрү.

3.18. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә:

юлламаны алган көннән башлап ун эш көненнән соңга калмаган срокта медицина таныклавын узу турында бәяләмәне халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән китерү кирәклеге турында;

әлеге пунктның икенче абзацында билгеләнгән срокта медицина таныклавын узу турындагы бәяләмәне мөрәҗәгать итүче тарафыннан шәхсән тапшырмауның хокукый нәтиҗәләре турында.

Бу мәгълүмат медицина таныклавын узу турындагы белдерүдә бар.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән сайлап алынган һөнәр (белгечлек) варианты алынганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмаган срокта башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә медицина таныклавын уздыру турында мәгълүмат җиткерү.

3.19. Дәүләт хезмәте күрсәтү мөрәҗәгать итүче медицина таныклавын уза торган вакытка туктатыла. Дәүләт хезмәтен туктату турында белдерү мөрәҗәгать итүчегә җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура медицина таныклавын узу кирәклеге турында белдерү җибәрелгән көннән соң киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору.

3.20. Халыкның мәшгульлек үзәге медицина таныклавын узу турында бәяләмәдә булган белешмәләрне «Работа в России» порталында терки.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче медицина таныклавын узу турында бәяләмә биргән көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: «Работа в России» порталында медицина таныклавын узу турындагы бәяләмә мәгълүматларын теркәү.

3.21. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан медицина таныклавын узуга юллама алынган көннән башлап ун эш көненнән соңга калмаган срокта медицина таныклавын узу турындагы бәяләмәнең халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән тапшырылмавы «Работа в России» порталында теркәлә. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу турыда мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче тарафыннан медицина таныклавын узу турында бәяләмә тапшырылырга тиешле көннән соң киләсе эш көне узмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату.

3.22. «Работа в России» порталы ярдәмендә мөрәҗәгать итүче белән һөнәр (белгечлек) сайлау һәм килештерү

Мөрәҗәгать итүче элегрәк сайланган һөнәр (белгечлек) буенча хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыруга карата каршылыклар булуы турында медицина таныклавын узу турында бәяләмәне тапшырган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүче белән, аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылырга мөмкин булган һөнәрне (белгечлекне) сайлау максатларында, һөнәрне (белгечлекне) сайлау һәм килештерүне яңадан гамәлгә ашыра.

Һөнәрне (белгечлекне) мөрәҗәгать итүче белән яңадан сайлау һәм килештерү мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча, халыкның мәшгульлек үзәгенә шәхсән килгән көнне, әлеге Регламентның 3.11-3.13 пунктларында билгеләнгән тәртиптә элегрәк сайланган һөнәр (белгечлек) буенча хезмәт эшчәнлеген башкаруга карата каршылыклар булуы турында мәгълүмат тапшырган очракта гамәлгә ашырыла.

Аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрнең (белгечлекнең) сайланган варианты турындагы белешмәләр «Работа в России» порталында теркәлә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүченең ихтыяры буенча, ул шәхсән килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрнең (белгечлекнең) сайланган варианты турында «Работа в России» порталында теркәү.

3.23. Белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеген һәм мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә укыту өчен белем бирү программалары исемлеген формалаштыру

Халыкның мәшгульлек үзәге белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар исемлеген һәм мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә укыту өчен белем бирү программалары исемлеген төзи.

Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларны һәм белем бирү программаларын сайлау «Работа в России» порталыннан файдаланып, белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар реестрыннан һәм гражданин сайлаган һөнәр (белгечлек) буенча һөнәргә укыту яки өстәмә һөнәри белем алу мөмкинлеген исәпкә алып башкарыла.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрнең (белгечлекнең) сайланган вариантын җибәргәннән соң  яисә медицина каршылыклары булмавы турында (кирәк булган очракта) медицина бәяләмәсе бирелгән көннән алып киләсе бер эш көненнән соңга калмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар исемлеген һәм мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә укыту өчен белем бирү программалары исемлеген формалаштыру.

3.24. Мөрәҗәгать итүче белән белем бирү эшчәнлеген башкаручы

оешманы килештерү

Мөрәҗәгать итүче белән белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманы килештерү максатларында, халыкның мәшгульлек үзәге «Работа в России» порталын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә түбәндәгеләрне җибәрә:

а) белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларның киңәш итеЛә торган исемлеген һәм мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә укыту өчен белем бирү программаларының киңәш итеЛә торган исемлеген;

б) мөрәҗәгать итүче өчен түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган белдерү:

белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешманың бер вариантын һәм гражданин сайлаган һөнәр (белгечлек) буенча укыту өчен белем бирү программасының бер вариантын сайлау кирәклеге турында;

«Работа в России» порталын кулланып, белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешмаларның киңәш итеЛә торган исемлеге алынган көннән соң киләсе ике эш көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешманың һәм укыту өчен белем бирү программасының сайланган вариантын җибәрү кирәклеге турында;

әлеге пунктның «б» пунктчасының икенче абзацында билгеләнгән срокта әлеге мәгълүматны җибәрмәүнең һәм укытуга юлламадан баш тартуның хокукый нәтиҗәләре турында.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче халыкның мәшгульлек үзәгенә аның буенча һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу гамәлгә ашырылачак һөнәрнең (белгечлекнең) сайланган варианты турында мәгълүмат җибәргәннән соң яки медицина каршылыклары булмавы турында (мондый бәяләмәне алу кирәк булган очракта) медицина бәяләмәсе бирелгән көннән алып киләсе бер эш көненнән соңга калмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманы мөрәҗәгать итүче белән килештерү.

3.25. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешманың сайланган варианты турында һәм укыту өчен белем бирү программасының сайланган варианты турында мәгълүматны мөрәҗәгать итүче сайлаган һөнәр (белгечлек) нигезендә киңәш итеЛә торган оешмалар исемлеге алынган көннән соң килә торган ике эш көне эчендә халыкның мәшгульлек үзәгенә җибәрмәү «Работа в России» порталында теркәлә. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатыла, бу турыда мөрәҗәгать итүчегә тиешле белдерү җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешманың сайланган варианты турында мәгълүмат җибәрергә тиеш булган көннән дә соңгы эш көненнән соңга калмаган срокта гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату.

3.26. Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмалар исемлегендә, мөрәҗәгать итүчегә кирәкле һөнәр (белгечлек) буенча белем бирү программалары турында мәгълүматлар булмаган очракта, халыкның мәшгульлек үзәге Россия Федерациясе законнары нигезендә белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмаларны сайлап алуны гамәлгә ашыра.

3.27. Шартнамә төзү максатларында мөрәҗәгать итүчегә белдерү җибәрү

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан сайланган һөнәр (белгечлек) нигезендә халыкның мәшгульлек үзәге:

а) һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау турында мөрәҗәгать итүче белән шартнамә проектын рәсмиләштерә;

б) мөрәҗәгать итүчегә укытуга юллама рәсмиләштерә;

в) бердәм цифрлы платформа аша мөрәҗәгать итүчегә һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау турында шартнамә төзү һәм укытуга юллама алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә килү көне турында белдерү җибәрә. Шартнамә төзү һәм белем алуга юллама алу өчен халыкның мәшгульлек үзәгенә бару датасы күрсәтелгән белдерү мөрәҗәгать итүчегә шартнамәне һәм юлламаны рәсмиләштерү көнендә җибәрелә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүчедән белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешманың сайлап алынган варианты алынганнан соң бер эш көненнән дә соңга калмаган срокта башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: шартнамә төзү һәм укытуга юллама алу турында мөрәҗәгать итүчегә юллама җибәрү.

3.28. Мөрәҗәгать итүченең шартнамәне төзү һәм укытуга юллама алу өчен билгеләнгән көндә һәм вакытта килмәве халыкның мәшгульлек үзәге тарафыннан, мөрәҗәгать итүче тарафыннан укытуга юллама алудан баш тарту буларак, «Работа в России» порталында теркәлә.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче шартнамә төзү һәм укытуга юллама алу өчен билгеләнгән дата һәм вакыт эчендә килмәгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүченең килмәвен «Работа в России» порталында теркәү.

3.29. Халыкның мәшгульлек үзәге мөрәҗәгать итүче белән төзелгән шартнамә турындагы белешмәләрне «Работа в России» порталына кертә.

«Работа в России» порталында һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алуга юллау төзелгән шартнамәләр реестры формалаштырыла һәм алып барыла.

Үтәү вакыты: процедура мөрәҗәгать итүче белән шартнамә төзелгәннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче белән төзелгән шартнамә турында «Работа в России» порталына мәгълүматлар кертү.

3.30. Халыкның мәшгульлек үзәге белем бирү эшчәнлеген башкара торган оешмадан алынган, мөрәҗәгать итүчене укыту турында түбәндәге белешмәләрне «Работа в России» порталына кертә:

мөрәҗәгать итүчене укырга кабул итү турындагы боерык хакында;

мөрәҗәгать итүченең өлгереше һәм дәресләргә йөрүе турында;

белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешмадан мөрәҗәгать итүчене куу турында боерык хакында.

Үтәү вакыты: процедура аларны алган көннән башлап киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: «Работа в России» порталына мәгълүматлар кертү;

3.31. техник хатаны (язу хатасын, басма хатаны, грамматик яки арифметик хатаны яки шуңа охшаш хатаны) төзәтү.

Техник хатаны төзәтү мөрәҗәгать итүче тарафыннан, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.31.1. Халыкның мәшгульлек үзәге белгече:

- дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне үзгәртеп рәсмиләштерә;

- мөрәҗәгать итүчегә аның гаризасында күрсәтелгән ысул белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмәне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар гаризаны теркәгән вакыттан алып бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хатаны төзәтү турында кабул ителгән, теркәлгән гариза, дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү турында яңадан рәсмиләштерелгән бәяләмә турында хәбәр итү.»;

4 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Административ регламентның үтәлешен контрольдә тоту формалары»;

4.2 пунктта «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2010 елның 8 ноябрендәге 972 номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар (физик затлар һәм эш бирүчеләр) регистрын алып бару тәртибенең» сүзләрен «Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының 2021 елның 6 декабрендәге 871н номерлы боерыгы белән расланган Халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затларның регистрларын алып бару тәртибен, шул исәптән аларга белешмәләр кертү тәртибен, чорларын һәм белешмәләр рәвешен, шулай ук халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган затлар регистрларында булган мәгълүмат төрләре исемлегенең» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Белешмә телефоннар, дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның (белешмәлек) кушымтасында китерелгән.»;

5 бүлек атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның, КФҮ, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 16 статьясының $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең, хезмәткәрләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе»;

5.2 пунктының икенче абзацында «дәүләт хезмәте» сүзләреннән соң «210-ФЗ номерлы федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән» сүзләрен өстәргә;

2 нче, 4 нче кушымталарны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Башка җирлектә укытуны да
кертеп, эшсез гражданнарны
һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри
белем бирүне оештыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

Үрнәк

Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәргә укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)
2. Җенесе
3. Туган көне
4. Гражданлыгы
5. ИНН
6. СНИЛС
7. Шәхесне раслаучы документ төре
8. Шәхесне раслаучы документ сериясе, номеры
9. Шәхесне раслаучы документны бирү датасы
10. Шәхесне раслаучы документ кем тарафыннан бирелгән
11. Элемтә ысулы:
   а) телефон
   б) электрон почта адресы (булган очракта)
14. Хезмәт күрсәтү урыны:
   а) Россия Федерациясе субъекты
   б) халыкның мәшгульлек үзәге:
13. Социаль статус

Инвалид

Инвалид балалар тәрбияләүче ата-ана, уллыкка алучы, опекун (попечитель)

Алты айлык эшсезлек чоры беткәч граждан

Хәрби хезмәттән киткән

Хәрби хезмәткәрләрнең һәм хәрби хезмәттән киткән гражданнарның хатыны (ире)

Гомуми белем бирү оешмаларын тәмамлаучы

Квалификацияле түгел, беренче тапкыр эш эзли (элек эшләмәгән)

Хәрби хезмәттән киткәннән соң өч ел дәвамында чакыру буенча хәрби хезмәт үткән

Анда һөнәргә укыту яисә өстәмә һөнәри белем алу турында шарт булган очракта, социаль контракт нигезендә дәүләт социаль ярдәмен алам

Россия Федерациясе чикләрендәге башка җирлектә урнашкан дәүләт органнарына дәүләт граждан хезмәте вазыйфасына ротация тәртибендә

билгеләнгән дәүләт граждан хезмәткәрләренең хатыны (ире)

Мәгълүматларны раслау:

Әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итүгә ярдәм итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатларында минем шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык белдерәм, шул исәптән түбәндәгеләр өчен дә:

- әлеге мөрәҗәгатьне дәүләт органына, халыкны эш белән тәэмин итү хезмәтенең дәүләт учреждениеләренә яисә мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрне хәл итү аның компетенциясенә карый торган вазыйфаи затка җибәрү;
- әлеге мөрәҗәгать буенча карар кабул итү һәм халыкны эш белән тәэмин итү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү максатыннан өченче затларга шәхси мәгълүматларымны тапшыру.

Башка җирлектә укытуны да
кертеп, эшсез гражданнарны
һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри
белем бирүне оештыру буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Үрнәк

Гражданинга дәүләт хезмәте күрсәтү турында бәяләмә

____________________________________________________________

____________________________________________________________

(гражданинның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта))

дәүләт хезмәте күрсәтелде:

____________________________________________________________

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә:

а) укыту өчен тәкъдим ителгән һөнәрләр исемлеге формалаштырылды:

| т/с | Укыту өчен тәкъдим ителгән һөнәрләр (белгечлекләр) исемлеге | Сайлау турында билге |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |

б) укыту өчен тәкъдим ителгән белем бирү программалары исемлеге

формалаштырылды:

| т/с | Программаның исеме | 1 нче программа | 2 нче программа |
|---|---|---|---|
| 1. | Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың исеме | | |
| 2. | Программа дәрәҗәсе (квалификация күтәрү программасы / һөнәри әзерлек программасы / хезмәткәр һәм эшчеләр һөнәре буенча һөнәри әзерлек программасы / эшчеләр һәм хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү программасы / эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программасы) | | |
| 3. | Программаның эчтәлеге (төп блоклар) | | |
| 4. | Укыту формасы (шәхси/көндезге-читтән торып) | | |
| 5. | Уку озынлыгы | | |
| 6. | Эшчәнлек режимы | | |
| 7. | Укуны башлау датасы | | |
| 8. | Укуны тәмамлау датасы | | |
| 9. | Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың адресы | | |
| 10. | Белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың телефон номеры | | |
| 11. | Сайлау турында билге | | |

в) укыту оештырылды:
төзелгән шартнамә(ләр), шартнамәнең номеры
белем бирү эшчәнлеген башкаручы оешманың исеме:
курс исеме:
укыту вакыты:
г) финанс ярдәме күрсәтелде:

Халыкны эш белән
тәэмин итү
хезмәтенең дәүләт
учреждениесе
хезмәткәре
_______________ ___________ _______________________________

| ________________ | ____________ | ________________________________ |
|---|---|---|
| (вазыйфа) | (имза) | (фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта)) |

«__» ________ 20__ ел.»;

(Белешмәлек) кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Башка җирлектә укытуны да кертеп, эшсез гражданнарны һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта».